**КАРАР**
Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
авыл җирлегенең Наратлы- Кичү Советы

№1 25.09.2018 ел

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Наратлы- Кичү авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы- Кичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2018 елның 18 сентябрендәге №17 Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы- Кичү авыл җирлеге Башкарма комитеты карары нигезендә

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Наратлы- Кичү авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Наратлы-Кичү авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2019 елда Наратлы- Кичү авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, Бөек Ватан сугышы тылы хезмәтчәннәре, күп балалы гаиләләрдән тыш, аларның саны торак пунктта яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиеш, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
-Исәнгол торак пунктында урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру, Наратлы- Кичү торак пунктында һәлак булган Бөек Ватан сугышы обелискын төзү.

"ӘЙЕ" "ЮК".

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Минзәлә муниципаль районының menselinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Минзәлә муниципаль районының Наратлы- Кичү авыл җирлеге башлыгы Минһаҗев Фәрәхетдин Хәмәтдин улына йөкләргә.

5. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районы
Наратлы -Кичү авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Минһаҗев